# Мәктәп хәбәрчесе

№2 (№43) февраль 2023 ел

Түбән Майна урта мәктәбе газете


Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru


*/Мөхәррир минбәре/*

## *“Разговоры о важном” – “Мөһим нәрсә турында сөйләшү”*




Ел саен мәгариф нинди дә булса үзгәреш, я яңалык белән башлана. Быелгы 2022-2023 нче уку елына министрлык тарафыннан “Разговоры о важном” – “Мөһим нәрсә турында сөйләшү” дип аталган тәрбияви юнәлеш кертелде. Уку елының беренче саныңда бу турыда искәртеп киткән булсак та, бераз тирәнрәк тукталасы иттек.

Мөһим темаларга сөйләшүләр Ватан, патриотик рух төшенчәсен укучыларыга житкерүдән гыйбарәт. Әлеге проект үз эченә сыйныф сәгатьләре тематикасын бирә: анда патриотизм, әхлакый тәрбия, табигатьне саклау, мөһим тарихи вакыйгалар белән бәйле төрле мәсьәләләр карала.

“Мөһим нәрсәләр турында сөйләшүләр” уткәрү идеясе 2022 елның 20 июнендә «Белем» җәмгыяте утырышында яңгырады. Җәмгыятьнең генераль директоры Максим Древаль проектның максаты – укучыларда Ватанга мәхәббәт, үз илебез өчен горурлык, патриотизм формалаштыру аркылы Россиянең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрен ныгыту дип билгеләде. Укучылар белән сөйләшүләр түбәндәге юнәлешләр буенча алып барыла:

- актив гражданлык позициясен тәрбияләү;
- милли кыйммәтләр нигезендә әхлакый һәм патриотик тәрбия бирү;
- яшьтәшләр белән аралашу күнекмәләрен һәм аралашу осталыгын камилләштерү;
- укучыларның гомуми культурасын күтәрү;
- туган як, Россия тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү һәм саклау белән кызыксынуларын тирәнәйтү;
- яшьтәшләр белән уртак эшчәнлек күнекмәләрен үстерү;
- коллектив эшчәнлектә катнашуның уңышлы булуын тәэмин итүче сыйфатлар булдыру;
- мәгълумати мохитта үз-үзеңне тоту культурасын формалаштыру.

Проектны төзүчеләр аңлатканча, «мөһим нәрсәләр турында сөйләшү» барышында балалар укытучы белән илнең тарихы һәм мәдәниятен, шулай ук аның төбәкләренең гореф-гадәтләрен һәм үзенчәлекләрен өйрәнәчәк. Барлык методик материаллар тәкъдим итү характерында булачак. Иң беренче «Мөһим нәрсә турында сөйләшүне" мәктәпләрдә 2022 елның 1 сентябрендә уткәрдек. Шуннан соң һәр атна башында даими уткәрелеп килә. Бу чаралар укучылар өчен эзсез калмас диеп ышанасы килә. Туган илне яратуга тырышып уку да, шәхси тәртибең дә керә.

*Фәнүзә Гафиятуллина, газетаның баш мөхәррире*

## 23 нче февраль – Ватанны саклаучылар көне



Хөрмәтле ир-егетләр! Сезне 23 нче февраль – Ватанны саклаучылар көне белән чын күңелдән котлыйбыз. Бу бәйрәм туган илен яратучылар, көчле рух, кыюлык, намус һәм абруй шикелле сыйфатларга ия булган затларны тәбрикли торган тантана. Туган илгә һәм үз халкыңа хезмәт итү – Ватанын чын күңелдән сөюче егетләр өчен горурлык. Сез илебез чикләрен генә түгел, гаиләбез тынычлыгын һәм иминлеген дә саклаучылар. Сезгә ныклы исәнлек, ихтыяр көче, күңел күтәренкелеге телибез. Алдагы тормышыгыз туган илебездә яраткан хезмәтегез белән барсын. Якыннарыгыз өчен горурлык, таяныч булып сәламәт яшәгез.

Егетләребезнең батырлыгын, көчен һәм тапкырлыгын 22нче февраль көнне узган бәйрәмдә сынадык. Бу чара 1-11 нче сыйныф егетләре катнашында хәрби-спорт төрләре буенча ярыш-эстафета рәвешендә уздырылды. Ә кызлар аларга көч биреп торды. Узган айда башлангыч сыйныф укучылары “Солдатка хат” чарасында катнашып, армиядә хезмәт итүче хәрбиләргә үз теләкләрен язып хатлар җибәрделәр.

Батыр, кыю егетләр
Үсә безнең мәктәптә.
Туган илен саклаучы
Булыр алар, әлбәттә.

Көчле булып үскәчтен
Ил чикләрен сакларлар.
Бер авырлык китермичә
Якыннарын якларлар.

*“Мәктәп хәбәрчесе” редколлегиясе*

*/Мәктәп тормышы/*

## *Хезмәт дәресендә*



Мәктәптә минем яраткан дәресләремнең берсе – хезмәт дәресе. Ни өчен дисезме? Чөнки хезмәт дәресендә нинди генә кул эшләренә өйрәнмибез. Ә иң әйбәт килеп чыккан кул эшләрен районга конкурсларга җибәреп, анда алдынгы урыннар да алабыз.

Менә бүген без дәрестә төрек милли ризыгы – шаурма ясау осталыгына өйрәндек. Шаурма пешкән ит, соус, тәмләткечләр һәм яшелчәләр салаты белән бергә юка җәймәгә, яки лавашка төреп ясала. Аның өчен мөселман халыклары сарык, тавык, күркә, сыер ите кулланалар. Без дә шул ризыкларны туплап алып килдек. Апаларыбыз бөтен эш тәртибе белән таныштырып, җитәкләп барды. Бергәләшеп үзебезнең шаурмаларыбызны әзерләдек. Тәмле булсын өчен ризыкның зәвыклы итеп әзерләнүенең да шарт икәнлегенә төшендек. Шаурмабыз бик матур да, телеңне йотарлык тәмле дә килеп чыкты.

Мондый эшләрне өйрәнү киләчәк тормыш өчен файдалы. Хәзер инде әниләр әйдә булмаганда ашарга әзерләп куя беләбез. Укытучы апаларга төрле эшләргә өйрәткәннәре өчен рәхмәт әйтәбез.

*Гөлсем Сафиуллина, II сыйныф укучысы*

*/Безнең спорт/*

## *Чаңгы ярышлары һәм эстафеталар*

Февраль аенда һава торышы барыбызны да шатландырды. Кояш җылы яктысын биреп тора, көннәр аяз. Мәктәптә һәр физкультура дәресе саф һавада үтте. Укучылар чаңгыда шуу һәм таудан төшү ысулларын яхшы үзләштерделәр. Без чаңгыда шуарга бик яратабыз. Ә барысыннан да бигрәк бу спорты башлангыч сыйныф укучылары ярата.

Хәрби-патриотик айлык булганлыктан, бу айда ярышлар күп булды. Шулар рәтеннән чаңгыда күңелле эстафеталар һәм чаңгы ярышы булып үтте. Башлангычлар арасында I урынны Хәбибрахмәнов Абдулла, II урынны Замалетдинов Зөлфәт алдылар. III урынга Камалов Илнур һәм Закиров Инсаф бергә килделәр. Урта сыйныфлар арасында Хасанов Станислав, Йосыпов Рәсим, Хәйруллин Айназ, Гафиятуллин Самат алдынгы урыннарны яуладылар. Урта һәм зур сыйныфлар арасында ату ярышы да булып узды. Хәбибрахмәнова Хәнифә белән Камалов Илдус иң күп очко тупладылар. *Төхвәтуллин Камил, V сыйныф укучысы*

........................................................................................................................................................................................................

24 февраль көнне Норлат районы Түбән Норлат авылында якташ сугышчы-интернационалист М.Бакиров истәлегенә багышланган билбау көрәше булып узды. Безнең көрәшчеләрдән турнирда Камалов Илдус белән Галимов Рияз катнаштылар. Ике егетебез дә үз авырлыкларында беренче урынны алуга ирештеләр. Әфәрин,егетләр!

## *Бер сүз белән әйт*

Алтын куллы – ...

Ут йоту – ...

Эттән алып эткә салу – ...

Утак тел табу – ...

Баш вату – ...

Колакка киртләү – ...

Кылны кылкка яру – ...

Балавыз сыгу – ...

Башы күккә тию – ...

Авызга су кабу – ...

Чәчләр үрә тору – ...
Су кебек эчү – ...

Җилләр исү – ...

Ике тамчы су кебек – ...

*/Күңелле тәнәфес/*

Борын күтәрү – ...

Багана саклау – ...

Бабил манарасын кору – ...

Авыр санлы – ...

Салпы якка салам кыстыру – ...

Кондырчалы кодагый – ...

Бәхет кошын тоту – ...

Күз карасы кебек саклау – ...

Авызны колак артына элү – ...

***Кем тизрәк һәм хатасыз җавап бирә, шуңа татар теленнән “5” ле билгесе куела!***


**Газетаны гамәлгә куючы** – Түбән Майна урта мәктәбе
**Мөхәррир** – Фәнүзә Гафиятуллина
**Редколлегия әгъзалары:** Әминә Туктамышева, Виктория Нукина, Зөлфирә Сафиуллина




***/Мәктәп тормышы/***

## *Муса Җәлилне искә алдык*

Февраль ае – халкыбызга Җәлилне биргән ай. “Дөньяда шундый итеп яшәргә кирәк: үлгәннән соң да үлмәслек булсын, яшәүнең бөтен максаты да шунда түгелмени”, – дип язган Муса Җәлил. Аның тормышы бу сүзләргә бик тә туры килә. Шуңа күрә ел саен халкыбызның герой шагыйре Муса Җәлилнең туган көнендә сыйныф сәгатьләре үткәрелә. Геройның сугышка кадәрле һәм сугыш чоры, әсирлектәге иҗаты өйрәнелә. Муса Җәлил – халкыбызның горурлыгы. Үзе үлсә дә исеме мәңгелек. Аның исемен урамнар, опера-балет театры, кечкенә шәһәр, хәтта кечкенә планета да йөртә. Без дә үз чиратыбызда халкыбызның шундый батыр уллары белән горурланабыз. Милләтебезне дөньяга таныттырган шәхесләребезне онытмабыз.

***Ләйсән Закирова,V сыйныф укучысы***

## *Батырлык дәресе*



Ватанны саклаучылар көне алдыннан һәр мәктәптә график буенча "Батырлык дәресләре" уздырыла. Яшь буын белән очрашулар ветеран сугышчыларның иҗтимагый оешмасы эшендә мөһим патриотик юнәлешләрнең берсе. 14 нче февраль көнне мәктәбебездә кунаклар белән очрашу үзенчәлекле үтте. Чарага ПДН инспекторы Фоат Абдуллин, Эчке эшләр министрлыгы ветераны Шамил Сәхабетдинов, РВСН ветераны Александр Евграфов һәм Россия Эчке эшләр министрлыгы һәм хәрби диңгез флоты ветераны, волонтер Анатолий Скворцов килде. Укучылар белән бергә алар патриотик әңгәмәләр алып бардылар. Шулай ук Ватанны саклаучылар көне турында сөйләделәр.

Балаларда төрле гаскәрләр флаглары белән хәрби формаларның барлыкка килүе зур кызыксыну уятты. Алар армиядә хезмәт итү, патриотизм һәм погоннлы кешеләрнең батырлыгы турында сөйләгәннәрен зур игътибар белән тыңладылар. Шамиль абый патриотик рухтагы җырлар җырлап безне рухландырды. Ватаныбызны яратырга өндәде. Илебезне сакларлык дәрәҗәгә ирешү өчен тырышып укырга, тәртипле булырга чакырды.

***Самат Гафиятуллин, IX сыйныф укучысы***



***/Безнең уңышлар/***

## *Туган тел көне чаралары*

Февраль аенда туган телләр көне билгеләп үтелә. Быел безнең мәктәп укучылары рус теленә багышланган зур конкурста катнашты. Бу ярыш бернична төрле номинацияне берләштерде.

20 нче февраль көнне Аксубайның 1 нче мәктәбендә Туган телләр көненә багышланган чарада районның 29 мәктәбеннән 80 нән артык укучы катнашты. Әлеге бәйрәмгә рус телендә сәнгатьле шигырь сөйләүчеләр җыелды. Конкурсның беренче өлеше булып, юбиляр шагыйрьләрнең шигырьләрен сәнгатьле башкару бурычы торды. Катнашучыларның барысы да җитди әзерләнгән иделәр, искиткеч чыгышлар ясадылар, үзләренең осталыкларын һәм шигырь башкаруның оригинальлеген күрсәттеләр. Безнең мәктәп укучылары да сынатмады. Жюри һәр катнашучыны игътибар белән тыңлап барды. Озак фикер алышканнан соң жюри нәтиҗәләрне игълан итте. Безнең укучылар да түбәндәге нәтиҗәләргә ирештеләр. **Закирова Ләйсән** (V сыйныф) – I урын, **Хусенов Дима** (III сыйныф) – III урын, **Шичкина Карина** (X сыйныф) – III урыннарны алуга ирештеләр. **Сафиуллина Гөлсем** (II сыйныф) сертификат белән бүләкләнде.

Шул ук чараның иҗади юнәлеше буенча безнең укучылар рәсемнәр конкурсында катнаштылар. Алар М.М. Пришвинның әсәрләренә иллюстрация ясап, менә шундый нәтиҗәләр яуладылар: **Нурматова Асия** (III сыйныф) – җиңүче, **Галиәскәрова Айшә** (II сыйныф) – лауреат. **Гафиятуллина Руфинә** (I сыйныф) белән **Закиров Инсафка** (II сыйныф) сертификатлар тапшырылды.

Л.Н.Толстой әсәрләренә багышланган презентацияләр конкурсында катнашкан **Морадимов Илсур** (X сыйныф) – призер исемен, ә **Вәлиев Ибраһим** (VI сыйныф) – лауреат исеменә лаек булдылар. **Нурматова Зәйнәп** (IX сыйныф) үзенең тел байлыгын “Рус халкының милли культурасы“дип аталган эсселәр конкурсында сынап, лауреат исемен алды.

***Гөлшат Закирова, башлангыч сыйныфлар укытучысы***



***/Безнең уңышлар/***

## *“Без бергә” бәйгесендә*

28 нче февраль көнне район үзәгендә “ Без бергә” дип аталган сәнгать фестивале булып узды. Бу мәдәни бәйге балаларның һәм яшүсмерләренең сәнгать-эстетик иҗатын үстерүгә юнәлдерелгән. Район буенча әлеге конкурста 300 дән артык укучы катнашкан.

Безнең мәктәп укучылары да бу бәйгедән читтә калмады. Чара турында мәгълүмат килүгә, балалар актив әзерләнә башлады. Ял көннәрендә мәдәният йортына килеп сәхнәдә чыгышларын кабатладылар. Тырышып әзерләнү нәтиҗәсендә, укучыларыбыз фестивальдә үзләренең талантларын югары дәрәҗәдә күрсәтә алдылар. Дәрес, укучыларда курку, хафалану хисләре дә бар иде. Кайберләре әле зур сәхнәдә беренче тапкыр гына чыгыш ясады. Әмма аңа да карамастан, балаларның берсе дә югалып калмады һәм номерларын сыйфатлы итеп күрсәтә алдылар.

Укучыларның концерт номерлары матур һәм истә калырлык иде. Жюри әгъзалары – мәктәптән тыш эшләр үзәге хезмәткәрләре – һәр чыгышны игътибар белән күзәттеләр. Тамашачылар да битараф калмады, чыгыш ясаучы һәм катнашучыларны кайнар алкышлар белән озаттылар. Безнең мәктәп укучылары үзләрен төрле номинацияләрдә сынап, түбәндәге урыннарга ирештеләр:

- "Иҗади гаилә" – бабасы белән Закиров Инсаф – II урын;
- "Аерым җыр" – Донсков Артур – III урын;
- "Халык вокаль ансамбле" – Закирова Ләйсән, Насыйрова Кәүсәр, Сафеева Настя триосы – III урын;
- "Сәнгатьле уку" – Насыйрова Кәүсәр – II урын;
- хореография – Залиева Вәсилә – II урын.

Шулайк ук “Сәнгатьле уку” номинациясендә Сафиуллина Гөлсем, Хусенов Дмитрий һәм Закирова Ләйсән матур чыгышларын күрсәттеләр.

Фестивальдә катнашкан укучыларга укуларында иҗатларында тагын да зуррак уңышларга ирешүләрен теләп калабыз. Балаларны әзерләргә булышкан укытучыларга һәм әти-әниләргә рәхмәтебезне белдерәбез.

***Гөлшат Закирова, башлангыч сыйныфлар укытучысы***

## *“Матур язам” конкурсы*



Безнең халыкның фикер сөреше шундый: әгәр матур, пөхтә язса, бала яхшы укучы, тәртипле булып санала һәм киресенчә. Шуңа күрәдер, ата-аналарның балаларын матур язарга өйрәтәсе килә. Ә өйрәтә алмаса, нишләргә? Гомумән, нәрсә соң ул «матур язу»?

Гомумән алганда, язуның «яхшы» яки «начар» дигән төшенчәсе юк. Шулай да, тышкы күренешенә карап матур яисә матур түгел дип бәяли алабыз. Кагыйдә буларак, язу формалашсын өчен шактый вакыт кирәк. Бала 5-6 яшендә язарга өйрәнә башлый гына әле. Тиешле язу күнекмәсе булмау сәбәпле, ул тиз яза алмый. Бу чорда бала хәрефне, сүзне ничек дөрес һәм матур итеп язу турында гына уйлый. Ә 11-12 яшьләрдә язуы үзгәрә, тизлеге дә арта. Ул инде текст эчтәлегенә игътибарын юнәлтә һәм аның язу рәвешендә эчке халәте дә чагыла башлый.

Үткән еллардагы кебек үк, быел да безнең мәктәптә “Матур язам” конкурсы булып үтте. Бәйгедә башлангыч сыйныф укучылары актив катнашты. Конкурс өч этаптан торды. Беренче этапта укучыларга алфавитны матур каллиграфик дөрес язу белән күчереп язарга һәм төрле логик биремнәрне үтәргә кушылды. Икенче этапта укучыларга махсус басма хәрефләр белән бирелгән шигырьне күчереп язарга һәм язу элементларын кулланып рәсем ясарга тәгъдим ителде. Өченче этапта балалар компьютерда, Word программасында текст җыйдылар.

Шундый күптөрле һәм кызыклы биремнәрне башкарып чыкканнан соң нәтиҗәләр ясалды. III сыйныфтан **Нурматова Асия** I урынны яулады. II сыйныф укучысы **Камалов Илнур** II урынга иреште. Ә III урынга II сыйныфтан **Закиров Инсаф** ия булды. Җиңүче һәм актив катнашкан укучыларга бүләкләр бирелде. Безне иң куандырганы шул булды – балаларның язулары үткән ел белән чагыштырганда шактый яхшырганлыгы ачыкланды.

***Сафия Хәбибрахманова, башлангыч сыйныф укытучысы***



***/Котлыйбыз!/***

Февраль аенда туган көннәрен билгеләп үтүче укучыларыбыз **Камалов Илнурны, Донсков Артурны, Хәбибрахманов Абдулланы, Хасанов Стасны, Йосыпов Рәсимне** ихластан котлыйбыз. Аларга укуларында уңышлар, ныклы сәламәтлек, тырышлык телибез. Ватанны саклаучыларны тәбрикли торган айда туган егетләребезнең әти-әниләренең горурлыгы булып үсүләрен теләп калабыз.